ПРОЕКТ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2026 елның «___» апреленнән № ____

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә узучы муниципаль маршрутлар буенча җайга салына торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны даими гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында пассажир йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2025 елның 18 мартындагы 75 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Норматив хокукый актларга, Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга һәм күрсәтелгән субсидияләр алучыларны сайлап алуны, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга салучы муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә узучы муниципаль маршрутлар буенча җайга салына торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны даими гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында пассажир йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2025 елның 18 мартындагы 75 номерлы карарына (2025 елның 25 июнендәге 147 номерлы, 2025 елның 14 ноябрендәге 245 номерлы, 2025 елның 15 декабрендәге 285 номерлы, 2026 елның 29 гыйнварындагы 14 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә узучы муниципаль маршрутлар буенча җайга салына торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны даими гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында пассажир йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибендә:

1.1. IV бүлекнең 4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Комиссия тапшырылган документларны 30 календарь көннән дә артмаган, әмма кимендә 10 эш көне дәвамында карый. Кисәтүләр булганда документлар мөрәҗәгать итүчегә 5 календарь көн эчендә кире кайтарыла.»;

1.2. IV бүлекнең 4.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5. Башкарма комитетның шәхси счетыннан пассажир йөртүченең счетына субсидияне күчерү карар кабул ителгән көннән алып 10 эш көне эчендә электрон рәвештә башкарыла.»;

1.3. V бүлекне түбәндәге эчтәлектә 5.3 пункт белән тулыландырырга:

«5.3. Пассажир йөртүче Федераль Үзәкнең 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары таләпләре буенча квартал тәмамланганнан соң 30 көн эчендә, квартал саен финанс отчеты һәм максатчан күрсәткечләр үтәлеше турындагы отчет (социаль эффект, экология күрсәткечләре) тапшыра».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов